1928 сәнә март 3дә Мәскәүдә чагымда газитәләр укыдым (Кәшшаф казый Тәрҗимани сөйли). Парижда бер ислам җәмгыяте бар. Шул җәмгыять Әфганистан әмирен каршы алуга ктнашканнар. Газитәләрдә күреп укыганнан соң Әфганистан әмирен каршы алу өчен безгә дә катнашырга тиешле күренде. Шуннан соң тышкы эшләр халык комиссарияте Чичерингә мөрәҗәгать иттем. Сичрин бик яхшы кабул итте һәм Уфадан телеграм белән чакырырга вәгәдә кылды. Мин Уфага кайтып киттем. Шуннан соң апрель ахырында Мәскәү хөкүмәтеннән Башкортстан хөкүмәтенә безне чакырып телеграм килде. Мөфти-хәзрәт белән апрель ахырында Уфадан чыгып киттек. Май башында Мәскәүдә булдык. Чичерин, Калинин, Ысталин һәм Луначарскийлар белән күрештек. Сичерин әйтә: Әфганистан әмирен каршы алырга ниндаен план төзедегез? – ди. Мин әйтәм: Без бер дә хәзерләнә алмадык, чөнки телеграмны бик кичектереп бирдегез. Сичерин әйтә: Без уйлаган идек, Варшавадан Төркиягә китәр дип. Ә ул Варшавадан монда килергә булган. Шул сәбәптән сезгә телеграм соң бирелде – ди. Алай булса да, күрешергә ничек уйлыйсыз? - ди.

// Мин әйттем: Без болай уйлыйбыз. Әүвәл каршы алыр өчен мәгшыят төзергә. Һәйәтемез: ун кешедән ким булмас. Күрешү хакында болай уйлыймыз: бер һәйәт төзергә һәйәтемез 20 кешедән артык булмас. Инде күрешкәннән соң кыйммәтле Коръән һидия итеп бирергә уйлыймыз – дидем. Ярый, бик яхшы, менә бу план үзе бик яхшы план – диде, ләкин шуны әйтергә тиешлемен, һәйәтегездәге кешеләрегез безгә мәгълүм кешеләр түгел. Без сезне беләмез, бу хакында сез мәсъүлсез – диде. Мин мәсъулиятне өстемә алдым. Шуннан соң Мәскәү имамы мелла Габделвөдүд хәзрәтләре белән күрешергә, шул хакта алар белән сөйләшергә булынды. Сөйләштек.

Без Әфганистан әмиренә 2 еллык Ислам мәҗәлләсе һидия итәргә алып барган идек. Аны аз сындык янә Мәскәүдән дуст-ишләр аркылы иске язма бер Коръән таптык. Зур кулда тарихи Коръән алтын белән язылган. Фарсыча тәрҗемәсе һәм язылган. Һәм ике еллык Ислам мәҗәлләсе. Шуларны бик яхшы төпләтеп һәм футләргә салып, кем тарафыннан вә кемгә һидия ителгәнен алтын белән өстенә язылды түбәндәгечә:

Падшаһе дәүләте галия Әфганистан Гали Әмануллаһ хан хәзрәтләренә. Шуралар иттифагындагы әһале исламның мәркәзе диния нәзарәтеннән тәкъдим ителде. 1342 нче сәнә 13 нче зөлкагъдә 1928 нче сәнә миляди 3 нче май.

Бу Коръән Шәриф 300 сумга төште. Шуннан соң Сичерин безнең Коръәнне соратып алды һәм күргәч бик яратты һәм гаҗәпсенде. «Бу бүген бездә калсын,» - диде. Калдырдым. Мәскәү хөкүмәте барысы да караганнар һәм яратканнар.

3нче майда сәгать 11ләрдә Әфганстан әмире килә дигән хәбәр алынды. Без кулымызга тиешле документларыбызны алып, һәйәтемез белән ике автомобильдә ултырып вокзалга киттек. Вокзалга барып керү белән хөкүмәтебезне каршы алды һәм тиешле урыннарга урын бирделәр. Вокзал ифрат бизелгән. //

Гаскәрләр шул кадәр киендерелгән, сөйләп бетерерлек түгел. Кием Германия формасында. Почетный карауллар бирелгән. Вокзалга хәтфә паласлар җәелгән иде.

11 сәгать тула башлагач, югары аеропланнар оча башладылар. Һәм бер аэроплан әмирне китерә торган поезд өстендә саклап килде. 11 тулуга килеп йиттеләр. Поездны каршы алу өчен музыка әфган гимны уйнап каршы алды һәм третий интернационал уйналды.

Шуннан соң вәрәшилделәр һәм Әфганстан әмире үзенең һәйәте белән төште. Шуннан соң бер офицер гаскәргә «Ысмирна!» командовать итте дә, кылычын катыннан чыгарып маңлай турсына куйды да Әфганстан әмиренә рапорт бирде.

Шуннан соң әмир гаскәр белән сәламләште һәм без дә сәлам бирдек. Ул да безгә сәлам бирде һәм баш ийде. Шуннан соң 2нче юл белән вокзалга әйләнеп керделәр һәм без дә кердек. Башка учреждениялярне кертмәделәр. Шуннан соң автомобильдә әмир өчен хәзерләнгән летний двор бахчага киттек. Беренче автомобильдә вәрәшилде (?) һәм әмир 2нче автомобильдә семьясе дүрт автомобильдә вәзирләр янә без ике автомобильдә. Шулай итеп Мәскәү беренче урамнарыннан киттек. Мәскәү халкы, безне күргәч әмир бөтен духовенствосы белән килгән икән дип уйлаганнар.

Шулай итеп 3нче майда әмирне үзенә хаслаган урынына калдырып, без дә үз номерларымызга // кайтып киттек. 2нче көн адресларны тәкъдим иттек. 3нче көн күрешергә барырга хөкүмәт тарафыннан әмер булды. Күрешергә бару өчен һәр сыйныфтан кеше алдык. Безгә кемне генә алсак та, ихтияр үз кулымызда иде. Барымыз 19 кешедән гыйбарәт бер һәйәт төзедек. Һәйәт башлыгы мөфти-хәзрәт иде. Дүрт автомобильдә ултырып дворецка барып кердек. Безгә почетный караул алып честь биреп каршы алдылар.

Ислам һәйәте әмир белән күрешергә килгәнлекне вәзире әмиргә хәбәр итте. Әмирдән керергә дигән хәбәр алынды һәм вәзир безне залга алып керде. Шуннан соң әмир чыгып безгә каршы сәлам бирде һәм ул мөфти-хәзрәт белән күреште. Соңнан барымыз белән күрешеп чыкты.

Шуннан соң мөфти-хәзрәт сүз башлап: Әткәгез Хәбибуллаһ хан белән дә бер мәртәбә күрешкән идем. Аллаһы тәгалә сезнең белән дә күрешергә нәсыйп итте. Синең белән күрешү шәрәфәтенә ирешүем өчен менә безнең тарафыннан һәдия дип Коръән белән «Ислам мәҗәлләсе»н тәкъдим итте.

Әмир хәзрәтләре дә Коръәнне алып һәм үбеп башына куйды.

Моннан соң беренче рәкамлы сәхифә башына күчәрсез...